| СОВЕТ СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| 08.11.2022ел | № 54 |

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 25нче декабрендәге 99 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында (2019 елның 29 апрелендәге 106 номерлы, 2020 елның 18 декабрендәге 16 номерлы үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына туры китереп, «Территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 19 июлендәге 01-16/5057 номерлы Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем алганда төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Урта Көшкәт авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 нче декабрендәге 99 номерлы (2019 елның 29 апрелендәге 106 номерлы, 2020 елның 18 декабрендәге 16 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның «Җирлек территориясен санитар чистарту» 3.1 пунктында (шәхси йорт биләмәләре территорияләрендә, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр территорияләрендә) сүзтезмәләреннән соң «юл сервисы объектлары» сүзтезмәсен өстәргә;

1.2. 16 статьяны «Кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту» 17 статья дип санарга;

1.2.1. 16 статьяның «Кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту» 16.1 пунктын 17.1 пункт дип санарга;

1.2.2. 16 статьяның «Кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту» 16.2 пунктын 17.2 пункт дип санарга;

1.2.3. 16 статьяның «Кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тоту» 16.3 пунктын 17.3 пункт дип санарга;

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 16 статья өстәргә:

«16 статья. Сервис объектларын карап тоту:

1. Сервис объектлары территорияләрен карап тоту мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Юл буе сервисы объектлары территорияләрен төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- уңайлы хәрәкәт итү өчен каты түшәмә;

- территорияне яктырту, архитектура-декоратив яктырту;

- аларны урнаштыру һәм карап тоту таләпләрен үтәп, бәдрәф кабиналары;

- чүп савытлары һәм чүп өчен кечкенә контейнерлар;

- яшелләндерү (газоннар, чәчәклекләр) һәм яшелләндерү бүлемтекләрен саклау элементлары (киртәләр).

3. Сервис объектларын урнаштыруга, аларны һәм аларга якын территорияләрне карап тотуга таләпләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

– керү-чыгу урыннарында, сервис объектларына керү юлларында күчеш-тизлек полосалары булырга тиеш;

– күчеш-тизлек полосаларында һәм сервис объектлары территорияләрендә тышкы яктырту булырга тиеш;

– хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгына төшү юлы юлдан су чыгару системасы белән бәйләнгән буй су чыгаргыч белән тәэминителерлек итеп төзекләндерелергә тиеш (төшү юлы астында су чыгаргыч торбалар урнаштырылырга тиеш);

– хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгының һәм аңа төшү юлларының буй авышлыгы юлдан капма-каршы якка юнәлтелергә тиеш. Түгәрәкләнү радиусы чикләрендә ул 20‰ тәшкил итәргә тиеш.

– мәйданчыкта һәм аңа төшү юлларында автомобиль юлы белән тигез дәрәҗәдәге камиллэштерелгән каты түшәмә булырга тиеш;

– ГОСТ Р 52289-2019 «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары. Юл билгеләрен, тамгаларын, светофорларны, юл киртәләрен һәм юнәлеш җайланмаларын куллану кагыйдәләре» таләпләре нигезендә юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары булу;

– Сервис объекты территориясендә эксплуатация һәм карап тоту барышында дефектларны бетерү ГОСТ Р 59292-2021 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Җәй көне карап тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары» һәм ГОСТ Р 59434-2021 «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Кыш көне карап тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль ысуллары» таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

– функциональ билгеләнеше буенча хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы территориясендә шул исәптән санитар-гигиена зонасы булырга тиеш;

– тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан тәртиптә булырга һәм бирелгән техник шартлар нигезендә эксплуатацияләнергә тиеш;

– юл буе сервисы объектларының транспорт чараларын вакытлыча кую урынында (стоянкасында) «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын бушлай кую өчен урыннар бирелергә тиеш.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар җирлекнең мәгълүмат стендында халыкка җиткергән (бастырып чыгарган) һәм Балтач муниципаль районының http://baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырган мизгелдән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю.М.